ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 510-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 510-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2297-VI ДС

проект
Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы $2^1$ пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш), № 96 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәп, үзгәреш кертергә:

«Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән акыл ягыннан артта калуның төрле формалары булган) балалар көндезге уку формасы буенча эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бер тапкыр уку хокукына ия. Күрсәтелгән затларга көндезге уку формасы буенча эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалары буенча белем алуның бөтен чоры дәвамында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә уку әдәбияты һәм язу кирәк-яраклары сатып алуга ел саен пособие һәм айлык пособие түләнә».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 29 маендагы 189-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнгән.

Әлеге Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләргә ярашлы рәвештә, ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән акыл ягыннан артта калуның төрле формалары булган) балаларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары акчалары хисабына көндезге уку формасы буенча эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалары буенча бер тапкыр уку хокукы бирелә.

Моннан тыш, әлеге категориядәге балаларга һәм алар арасыннан булган затларга уку чоры дәвамында уку әдәбияты һәм язу кирәк-яраклары сатып алуга пособие һәм айлык пособие түләнә, аларның күләме һәм түләү тәртибе Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм (яки) Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

Моңа бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына тиешле үзгәреш кертү күздә тотыла.

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларына үзгәрешләр кертү таләп ителә:

«Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары;

«2024-2026 елларга төп белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын яки анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмен раслау турында» 2023 елның 15 сентябрендәге 1143 номерлы;

«2014-2025 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 23 декабрендәге 1023 номерлы.

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән (шул исәптән акыл ягыннан артта калуның төрле формалары булган) балаларны көндезге уку формасы буенча эшчеләрне һәм хезмәткәрләрне яңадан әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбенә бер тапкыр укыту белән бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы тармак министрлыкларына дәүләт йөкләмәләрен үтәүгә каралган акчалар кысаларында һөнәри белем бирү оешмалары тарафыннан гамәлгә ашырылачак. Агымдагы елда көндезге уку формасы буенча яңадан әзерләү программасын ятим балалар арасыннан 1 кеше үтте.

Уку әдәбияты һәм язу кирәк-яраклары сатып алуга еллык пособие күләмен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 15 сентябрендәге «2024-2026 елларга төп белем бирү программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын яки анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмен раслау турында» 1143 номерлы карарында каралган шундый ук күләмдә билгеләү күздә тотыла: 2024 елга 3 339 сум.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының югарыда күрсәтелгән карары белән билгеләнгән төп һөнәри белем бирү программалары буенча көндезге уку формасында белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга, уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын яки анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга айлык пособиене айлык стипендиягә тиң күләмдә билгеләргә тәкъдим ителә: 2024 елның 1 сентябренә кадәр - 1 110 сум, 2024 елның 1 сентябреннән-1 155 сум.

Күрсәтелгән чыгымнарны финанслау «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга уку әдәбияты һәм язу кирәк-яраклары сатып алуга һәм аларга айлык стипендия бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетында ел саен каралган акчалар кысаларында гамәлгә ашырылачак.

2024 елга Татарстан Республикасы бюджетында югарыда күрсәтелгән категорияләргә айлык стипендиягә 33 750,0 мең сум, уку әдәбияты һәм язу кирәк-яраклары сатып алуга еллык пособиегә – 7 738,0 мең сум планлаштырылган/